ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 344-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 345-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 340-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 343-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 331-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 334-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 338-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 339-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 9 һәм 10.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 148135-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт (муниципаль) йөкләмәләре нигезендә юл эшләрен башкару максатларында гомумтаралган файдалы казылмалар бирүнең гадиләштерелгән тәртибен билгеләү өлешендә).

11. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 173718-8 номерлы федераль закон проекты турында (магистраль газүткәргечләрдән дискриминацияләнмәгән файдалану мөмкинлеге кагыйдәләрен (тәэмин итү тәртибен) яисә аларга тоташуның билгеләнгән тәртибен (технологик тоташуны) бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 13 октябре
№ 1633-VI ДС